| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

25.01.2024 Кошман ав. № 70

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 23 номерлы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96_6 һәм 220_1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 02 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 октябрендәге 23 номерлы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәнең 22 статьясындагы 3 пунктының, 25 статьясындагы 3 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга;

2) 36 статьяда:

- беренче абзацта «программаны раслаган Җирлек Башкарма комитеты муниципаль хокукый акты нигезендә» сүзләрен «Җирлек Башкарма комитеты билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

- икенче абзацта «билгеләнгән срокларда» сүзләрен «билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

- өченче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

"Муниципаль программалар чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет турындагы карарга чираттагы финанс елы башланганчы туры китерелергә тиеш.";

- түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

муниципаль программалар бюджет турындагы канунга (карарга) агымдагы финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча туры китерелергә тиеш.";

3) 37 статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Кошман авылы җирлеге Башлыгы** **Л.Р. Сафина**